**<u>Муса Җәлил</u>**

## Мәхкүм

Хөкем булды бүген, аны үлем
Җәзасына хөкем иттеләр.
Ул еламый, соңгы күз яшьләре
Күптән инде агып киптеләр...

Төрмә тып-тын; моңсу караш белән
Күктән карый тулган ай гына.
Ә ул, мескен, балам — йөрәк парәм
Ятим үсә, диеп кайгыра.

**1943 ел**